«Мин татарча сөйләшәм” акциясе

*Татар теле минем туган телем,*
*Сөйләшүе рәхәт ул телдә.*
*Шул тел белән көйлим...*
*Шул тел белән сөйлим*
*Милләттәшем булган һәркемгә.*


# Тамчы

**Икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе**

Апрель №15 (58)     2015-2016 уку елы





«БЕЗ «ТЕМА»ДА!» ДИП БАШЛАРГА ТЕЛӘДЕК БЕЗ БУ НОМЕРНЫ. ЧӨНКИ БАР ТАТАРСТАН ХӘЗЕР ҮЗ ТЕЛЕН, ҮЗ МИЛЛӘТЕН АЛГА КУЯРГА ТЫРЫША.

Дөньяви, халыкара чараларда үзебезне күрсәтеп, шактый уңышларга ирешәбез! Ниһаять, мәгариф, мәдәният, әдәбиятыбыз, көнкүрешебез белән таныштырабыз.

Монда — татар конгрессының роле бик зур. Алар «Мин татарча сөйләшәм» акциясен алып бара. Без киммени?

Республика күләмендә үткәрелә торган **"Мин татарча сөйләшәм"** акциясендә катнашу мәктәбебез өчен яңалык түгел. Соңгы дүрт елда без бу актуаль чарада актив катнашабыз. Ике тапкыр җиңү дә яуладык. Тик үзмаксат, әлбәттә, җиңү түгел, ә укучыларны, бистәдәшләребезне күбрәк татарча аралашырга, татар сәнгате, мәдәнияте белән танышырга өндәү, туган телебезнең куллану даирәсен арттыру, киңәйтү һәм аның киләчәге турында уйлану.

Сәбәбебездә юк түгел. Сарман ягы - Татарстанның татар районы гына түгел, ә шагыйрь, язучылар саны буенча, Арчадан гына калышы торган район бит ул. Районыбызда ике генә рус авылы булган. Бу Петровка һәм Александровка авыллары. 2014 нче елда үзенең 45 еллыгын бәйрәм иткән бистәдә бүген 15 меңнән артык кеше яши. 3 мәктәп, 6 балалар бакчасы эшли. Тик аларның берсе дә татар мәктәбе, татар балалар бакчасы түгел. Белем бирү рус телендә алып барылган белем учакларында милли горурлык хисләре тәрбияләү, милли үзаңны үстерергә кирәк. Моның өчен "Мин татарча сөйләшәм" акциясе – зур мөмкинлекләр бирә. Уйлан, тәкъдим ит, җәлеп ит, үз янына теләктәшләрне җый һәм алга!




«Челтериләр Җәлил чишмәләре» дип аталучы чарада мәктәпкүләм презентацияләр бәйгесе

## Акция көндәлеге

*Дәвамы икенче биттә*




Халыкара туган тел көнендә 1 нче сыйныф укучылары арасында **“Газиз туган телем”** дигән интеллектуаль викторина үткәрелде. Укучылар туган тел турында шигырьләр сөйләделәр, ребуслар, кроссвордлар чиштеләр.

**29. 02**

Муса Җәлилнең 110 ел тулуына багышланган **«Тамчы-шоу»** бәйгесе оештырылды.




**«Нәүрүз»** бәйрәме булды. Язгы каникулга китәр алдыннан, шаулап-гөрләп Кышны озаттык. Быелгы бәйрәмне ике милләтнең уртак бәйрәме шикелле оештырдык. Яз кызы – Нәүрүзбикәне дә каршы алдык, шамакайлар да кунакка килде. Тагын... Тагын ишеп-ишеп кар яуды.

**6.04**

Татар теле укытучысы Г. Шәһвәлиева җитәкчелендә **милли ризыклар күргәзмәсе** оештырылды.

## Акция көндәлеге

*Башы беренче биттә*

Апрель аена кадәр бистәкүләм **«Татар дозор»** марафоны (сораштырулар), «Татар исемнәрен саклыйк», «Татар уеннары бездә кунакта» , «Туганлык атамаларын белергә телисезме?» , «Минем гаиләм шәҗәрәсе» акцияләре үтте. Алар арасында яңа чаралар да күп. «Татарча хатасыз» фотомарафонын да онытмыйк тагын!




Көлке көне уңаеннан 5 нче сыйныф укучылары **ШТК уенында** булдылар.
Алар шаянлыкта, тапкырлыкта, зирәклектә көч сынаштылар. Командалар яңгыраткан татарча мәзәкләр, күрсәткән этюдлар кызык булды. Татар халык мәкальләрен дә күп беләләр икән бишенчеләр! Афәрин!




**15. 04** Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ә. Гарифуллина карамагында —**Тукай әсәрләрен сәхнигеәлештерү буенча бәйге**.

**“Тукай экиятләре иленә сәяхәт” акциясе**



Сез татар халкының җырлы-биюле уеннарын беләсезме? Белмисез икән, өйрәнегез! Кем өйрәтәме? Җәлил Ветераннар советы каршында оешкан **Ак калфак ансабле** апалары! Алар шулкадәр күп уеннар, җырлар беләләр. Безгә дә шул уеннарны кучтәнәчкә алып килделәр. Безнең белән рәхәтләнеп уйнадылар алар!

**22.04 «Челтериләр Җәлил чишмәләре»** мәктәпкүләм бәйгесе, Халыкара Җир көне уңаеннан чара оештырылды. Чарада “Җәлилнефть” нефть һәм газ чыгару идарәсе экология бүлеге белгече, “Җәлил чаткылары” әдәби берләшмәсе әгъзалары катнашты.







**26.04** 26 нчы апрельгә кадәр мәктәптә, бистәдә Тукай шигырьләрен укучыларны барладык. Бүләккә – жетон. Бәйгегә йомгак **“Тукай яшь безнең йөрәкләрдә”** дип аталучы зур тантанада ясалды. Мәктәптән җиңүчеләр: 2 нче в сыйныфы укучысы Нуртдинова Наилә, 6 нчы в сыйныфы укучысы Фазлыева Зәринә, 10 нчы б сыйныфы укучысы Нуртдинова Ландыш.

“Мин татарча сөйләшәм” акциясенең район этабында без актив катнаштык. Тукай туган көнгә багышланган чараларны йомгаклап, бистә китапханәсе 27 нче апрель көнне әдәби-музыкаль чара оештырды. Чарада мәктәбебез укучылары әдәби композиция күрсәттеләр. Чара бистә шагыйрьләренең чыгышлары, биюләр, җырлар белән үрелеп барды. Укучылар зур бүләккә – Хәсән Туфанның 5 томлыгына ия булды. Мәктәбебезгә педагогик династияләр турындагы җыентык тапшырылды.




**Шеф редактор**: Шәйдуллина Ландыш Камиловна
**Редколлегия**: Ихсанова Ләйсән, Насыйбуллина Гөлфия (11А), Әлмиева Резидә, Гарифуллина Аделя, Гыйлфанова Раилә, Шәйдуллина Айгөл, Шәйхрамов Ленар (8 кл)
Дизайн: Әлмиева Резидә